«РАСЛЫЙМ»

Татарстан Республикасы
мәгариф һәм фән министры
_____ Э.Н. Фәттахов
" 6 " февраль 2015 нче ел

ТАТАР ТЕЛЕ

Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының
татар төркемнәрендәге IX сыйныф укучыларына
2015 нче елда татар теленнән бердәм республика тестларын
үткәрүгә әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр һәм эчтәлек
элементларының кодификаторы

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы
тарафыннан әзерләнде

Рус теленде гомуми белем бирүче мәктәпләрнең татар төркемнәрендәге IX сыйныф укучыларына, 2015 нче елда татар теленнән бердәм республика тестларын үткәрүгә әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторы

Татар теленнән әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторы (алга таба – кодификатор) 2015 нче елда бердәм республика тестларын үткәрүнең эчтәлеген билгеләүче документларның берсе. Кодификатор ике бүлектән тора:

1 нче бүлек – төп гомуми белем бирү мәктәбе курсы буенча татар теленнән бердәм республика тестларында тикшерелә торган эчтәлек элементлары исемлеге;

2 нче бүлек – төп гомуми белем бирү мәктәбе курсы буенча татар теленнән бердәм республика тестларына әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр исемлеге.

Кодификаторда Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслекләргә, белем бирү программаларына кертелмәгән әзерлек дәрәҗәсе таләпләре чагылыш тапмый.

Бу документ татар теле буенча төп гомуми белем бирү мәктәп курсы кысаларында бердәм республика тестларын төзү өчен нигез булып тора, шуңа күрә уку материалын гомумиләштерү һәм системалаштыру принципларыннан гыйбарәт.

1 нче бүлек. Төп гомуми белем бирү мәктәбе курсы буенча татар теленнән бердәм республика тестларында тикшерелә торган эчтәлек элементлары исемлеге

Бүлек коды	Тикшерелә торган элемент коды	Тикшерелә торган материалның эчтәлеге
1		***Фонетика***
	1.1	Аваз һәм хәреф
	1.2	Сүзгә фонетик анализ
2		***Лексика һәм фразеология***
	2.1	Сүзнең лексик мәгънәсе
	2.2	Антонимнар. Омонимнар. Синонимнар
	2.3	Фразеологик әйтелмәләр
	2.4	Кулланылышы ягыннан татар әдәби теленең сүзлек составы

	2.5	Килеп чыгышы ягыннан татар әдәби теленең сүзлек составы
3		***Сүз төзелеше, сүз ясалышы***
	3.1	Сүзнең тамыры һәм кушымчалар
	3.2	Сүз ясалу ысуллары
	3.3	Сүзнең ясалышын тикшерү
	3.4	Сүзнең төзелешен тикшерү
4		***Грамматика. Морфология***
	4.1	Мөстәкыйль сүз төркемнәре
	4.2	Ярдәмче сүз төркемнәре
	4.3	Сүзгә морфологик анализ
5		***Грамматика. Синтаксис***
	5.1	Сүзтезмә
	5.2	Җөмлә. Җөмләнең грамматик (предикатив) нигезе. Баш кисәкләр (ия, хәбәр)
	5.3	Иярчен кисәкләр
	5.4	Бер составлы һәм ике составлы җөмләләр
	5.5	Җыйнак һәм җәенке җөмләләр
	5.6	Тулы һәм ким җөмләләр
	5.7	Гади җөмлә
	5.8	Кушма җөмлә
	5.9	Тезмә кушма җөмлә
	5.10	Иярченле кушма җөмлә
	5.11	Туры һәм кыек сөйләм
	5.12	Сүзтезмәгә синтаксик анализ
	5.13	Гади җөмләгә синтаксик анализ
	5.14	Кушма җөмләгә синтаксик анализ
6		***Орфография***
	6.1	е, ю, я хәрефләренең дөрес язылышы
	6.2	о-ы, ө-е хәрефләренең дөрес язылышы
	6.3	в хәрефенең дөрес язылышы
	6.4	ъ-ь билгеләренең дөрес язылышы
	6.5	къ-гъ, к-г авазларын дөрес язу кагыйдәләре
	6.6	э хәрефенең дөрес язылышы

	6.7	сүз азагындагы [п] һәм [к], [къ] авазларының дөрес язылышы
	6.8	Дифтонгларның дорес язылышы
	6.9	Сүзләрне юлдан юлга күчерү кагыйдәләре
	6.10	-ия, -ие, -ль гә беткән алынма сүзләрнең дөрес язылышы
	6.11	Баш хәрефләрне язу кагыйдәләре
	6.12	Саннарның дорес язылышы
	6.13	Инфинитивның дөрес язылышы
	6.14	Кисәкчәләрнең дөрес язылышы
	6.15	Тезмә, парлы, кушма сүзләрнен дөрес язылышы
	6.16	Кушымчаларның дөрес язылышы
	6.17	Орфографик принциплар
7		***Пунктуация***
	7.1	Ия белән хәбәр арасында тыныш билгесе
	7.2	Гади җөмләдә тыныш билгеләре
	7.3	Тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләрс
	7.4	Эндәш һәм кереш сүзләр янында тыныш билгеләре
	7.5	Аерымланган кисәкләр янында тыныш билгеләре
	7.6	Аныклагычлар янында тыныш билгеләре
	7.7	Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләрс янында куела торган тыныш билгеләре
	7.8	Туры сөйләм һәм диалогта тыныш билгеләре
	7.9	Гомумиләштерүче сүзләр янында тыныш билгеләре
	7.10	Кушма җөмләдә тыныш билгеләре
	7.11	Теркәгечле тезмә кушма жөмләдә тыныш билгеләре
	7.12	Теркәгечсез тезмә кушма җөмләдә тыныш билгеләре
	7.13	Аналитик иярчен җөмләле кушма жөмләдә тыныш билгеләре
	7.14	Синтетик иярчен жөмләле кушма жөмләдә тыныш билгеләрс
	7.15	Катлаулы кушма жомләдә тыныш билгеләре
	7.16	Тезем һәм чит сөйләмле текстларда тыныш билгеләре
	7.17	Диалогта тыныш билгеләре
	7.18	Туры һәм кыек сөйләм янында тыныш билгеләре

	7.19	Татар һәм рус телләрендә пунктуация үзенчәлекләре
8		***Сөйләм***
	8.1	Сөйләм культурасы һәм тәрҗемә
	8.2	Татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү
	8.3	Рус теленнән татар теленә тәрҗемә итү
	8.4	Стильләр һәм сөйләм төрләре
	8.5	Стильләрнең лексик-грамматик үзенчәлекләре
	8.6	Төрле стильдәге һәм сөйләм төрендәге текстлар төзү
9		***Тел нормалары***
	9.1	Орфоэпик нормалар
	9.2	Лексик нормалар
	9.3	Грамматик нормалар (морфологик нормалар)
	9.4	Грамматик нормалар (синтаксик нормалар)
10		***Татар сөйләменең матурлыгы***
	10.1	Татар әдәби теленең байлыгы һәм тәэсирле булуы
	10.2	Лексика һәм фразеологиянең тәэсирлелек чаралары
11		**Төрле стильдәге һәм жанрдагы текстларны тикшерү**

2 нче бүлек. Төп гомуми белем бирү мәктәбе курсы буенча татар теленнән бердәм республика тестларына әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр исемлеге

Талән коды	Тикшерелә торган күнекмәләрнең исемлеге
1.	Сүзнең аваз-хәреф монәсәбәте үзенчәлекләрен белү
2.	Сөйләмне татар әдәби теленең әйтелеш (орфоэпик) нормалары ягыннан бәяли белү
3.	Сөйләмне татар әдәби теленең лексик нормалары ягыннан бәяли белү
4.	Сөйләмне татар әдәби теленең морфологик нормалары ягыннан бәяли белү
5.	Сөйләмне татар әдәби теленең синтаксик нормалары ягыннан бәяли белү
6.	Сөйләмне аңлап, дорес тәрҗемә итә белү
7.	Грамматик билгеләренә нигезләнеп, сүзнең билгелә бер сүз төркемена каравын билгели белү
8.	Лексик билгеләренә нигезләнеп, сүзнең билгелә бер сүз төркемена каравын билгели белү
9.	Сүзгә фонетик анализ ясый белү
10.	Фонетика, лексика, сүз ясалышы, морфология, синтаксис буенча алган белемнәрен телнең орфографик нормаларына яраклаштырып куллана белү

11.	Тыныш билгеләренең куелышын аңлата белү
12.	Сөйләм эшчәнлеге барышында, татар теленен синтаксик нормаларыннан тайпылмау
13.	Язма сөйләмдәге мәгълүматны дөрес, төгәл аңлый белү
14.	Сөйләм стильләрен билгели белү
15.	Сүз ясалышы ысулларын билгели белү
16.	Сүзтезмәләргә синтаксик анализ ясый белү
17.	Җөмләгә синтаксик анализ ясый белү
18.	Текстның эчтәлеге турында кыскача төгәл мәгълүмат бирә белү
19.	Башлангыч текстның эчтәлеген аңлый һәм аңлатып бирә белү
20.	Башлангыч текстка нигезләп,үз фикереңне әзлекле белдерә белү
21.	Үз фикереңне әзлекле, бәйләнешле белдерә алу
22.	Сөйләмдә телнең лексик байлыгыннан, төрле грамматик конструкцияләрдән урынлы куллана белү
23.	Язма һәм телдән сөйләмне әдәби телнең орфографик, грамматик һәм пунктуацион нормалары нигезендә тези белү